ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 23, с.Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 23 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)94-2-37, факс (84366)94-2-37. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**«22 » декабрь 2021 ел** **№ 32**

**Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчалары җыю Тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы составына керә торган торак пунктларда халык җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» Апаз авыл җирлеге Советының 2021 елның 28 октябрендәге 52 номерлы карары нигезендә 2021 елның 08 ноябрендәге № 1, 2021 елның 08 ноябрендәге № 2, 2021 елның 09 ноябрендәге № 3, 2021 елның 11 ноябрендәге № 4, 2021 елның 11 ноябрендәге №5, 2021 елның 12 ноябрендәге № 6 җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатыннан, Апаз авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчалары җыю Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм ТР, Арча районы, Апаз авылы, Совет урамы, 19 йорт; ТР, Арча районы, Хәсәншәех авылы, Космонавтлар урамы, 20 йорт; ТР, Арча районы, Пөшәңгәр авылы, Чапаев урамы, 42А йорты, Чапаев урамы, 33 йорт; ТР, Арча районы, Мирҗәм авылы, Н.Сафин урамы, 36 йорт адреслары буенча гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Апаз авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 нчы елның 18 декабрендә чыккан 28 нче номерлы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында"

карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Апаз авыл  җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов

Апаз авыл җирлеге
Башкарма
комитетының 22
декабрь 2021 ел, № 32
карарына
1 нче кушымта

**Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчалары җыю Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә күрсәткән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 2022 елның 12 февраленә кадәр муниципаль берәмлек территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Аерым категория гражданнар өчен:

а) көндезге уку формасы буенча укучы студентлар,

б)1 төркем инвалидлар,

в) 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен

түләү күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

4. Нигезле сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының үлеме (ата-ана, хатыны/ире, балалары),

б) янгын яки башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсенә зыян килү,

гражданнарга гариза нигезендә өч айдан да артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

5. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәр (хәбәрнамә) бланкы гражданнар игътибарына (http://pravo.tatarstan.ru) сайтында басылып чыгу юлы белән хәбәр ителә һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында ( http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмати стендларда, шулай ук кул куйдырып үзенә тапшыру яисә почта аша җибәрү юлы белән халыкка җиткерелә.

Хәбәрдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерү өчен түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчермәләрен (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла, «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты кассасы яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша сылтама https://uslugi.tatarstan.ru/ буенча башкарыла.

8. Түләүне дәлилли торган документ булып керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Апаз авыл җирлеге
Башкарма
комитетының 22
декабрь 2021 ел, № 32
карарына
2 нче кушымта

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______________
«Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча
бер мәртәбә түләнә торган түләү турында

Түләүченең ф. и.
а.и.______________________________________________________
Адресы:____________________________________________________________
___________________________________________________________нигезендә
Сезгә __________ кадәр ________ сум күләмендә
___________________________________чаралар гамәлгә ашыру өчен
түбәндәге реквизитлар буенча:
БИК банк __________________________
Сч. № ______________________________________
Счетны алучы. № ______________________________
ИНН __________________________________________
КПП __________________________________________
КБК _________________ОКАТО__________________
Түләү билгеләнеше
___________________________________________________бер тапкыр түләү
түләргә кирәк.

Җитәкче _________________ ____________________________________
М. у. (имза) ( имзаны аңлату)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

«Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына __ сум күләмендә бер мәртәбә түләнә торган үзара салым түләү буенча хәбәр (хәбәрнамә) № ___
Түләүченең ф. и. а.и.__________________________________________
Адресы: ________________________________________________
Алдым «___» _______________ 20__ ел
____________________________________
(имза/түләүченең ф.и.а.и.)

*Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән бирелгән очракта, өзмә корешок тутырыла һәм ул Апаз авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*